ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

01 июль 2021 ел № 4400

Башкарма комиетның 2021 елның 26 мартындагы 2088 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасына үзгәрешләр кертү турында

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 18 апрелендәге 2342 номерлы карары, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Мниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасын раслау турында» 2021 елның 26 мартындагы 2088 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасына, аңа кушымтада каралганча 59 пункт өстәп, үзгәрешләр кертергә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Н.А. Кропотовага йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2021 елның 1 июлендәге
4400 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә сезонлы стационар булмаган сәүдә объектларын һәм җәмәгать туклануы объектларын урнаштыру схемасы

| № т/б | Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны | Объектның тибы | Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының махсуслашуы | Сезонлы стационар булмаган сәүдә объектының урнашу урыны координатлары |
|---|---|---|---|---|
| Җәмәгать туклануы хезмәтләре күрсәтү объектлары | | | | |
| Автозавод районы | | | | |
| 59 | Вахитов проспекты, 22 йорт, «Вай Гоги» кафесының җәйге верандасы | Җәйге веранда (51,2 кв.м) | Җәмәгать туклануы хезмәтләре | 471173,56 2324506,70<br>471172,84 2324505,96<br>471185,98 2324493,16<br>471186,11 2324493,30<br>471175,98 2324503,17<br>471176,56 2324503,76<br>471173,56 2324506,70 |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева